Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

1 апрель, 2020 ел № 61

2020 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында

«2020 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турында» Татарстан Республикасы кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе мәгълүматын тыңлап, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 2020 елда Татарстан Республикасында һәм Питрәч муниципаль районында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Питрәч муниципаль районы милкенең барлык рәвешләрендәге учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе мәгълүматын исәпкә алуны, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен бозу очракларын булдырмау чараларын күрүне, халыкны хокукый агартуга юнәлдерелгән чараларны активрак үткәрүне тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов